Хатын-кызлар, балалар кич утырырга җыелган. Кемдер бәйли, чигә, тегә—фронтка посылка әзерлиләр. Кайберәүләр хат яза. Үзләре иңенә төшкән авырлыклар хакында да сөйләшеп алалар. Аларның берсе байтактан инде хат ташучының күренмәве хакында әйтә. Найрә Сабитова Гитлер турында такмаклар җырлый. Ләйсән Гыйззәтуллина, Фәнис Дәүләтшин, Лилия Якупова дәртле биюләре белән һәркемнең күңелен күтәрә.



Биюләр арасында апалар «Кердем карурманнарга» дигән моңлы җырны башкаралар. Бусагада хат ташучы Нәсимә күренә һәм фронттан килгән хатларны тарата. Мәликәнең улы Кызыл Байрак орденына лаек булган, аның өчен барысы да шатлана. Улы өчен горурланган ана шатлыктан күз яшьләрен сөртә. Зөләйха иреннән хат алган. Ул яраланып, госпитальдә ята икән. Хатын-кызлар хат ташучыга фронтка әзерләгән посылкаларын тапшыралар. Аннан соң «Өчле», «Дүртле», «Бишле», «Капка» кебек фольклор биюләре, «Җебегән», «Балдак салу» уеннары башлана. Ирина Мансурова, Флорида Габдрахманова, Найрә Сабитова, фольклор коллективы башкаруында «Җомга көе», «Порт-Артур», «Яшь наратлар», «Каз канаты» җырлары яңгырый. Театрлаштырылган тамашаны Зөһрә Фәрхетдинова башкаруында «тере» музыка—гармун моңы бизәде.

Кич утыру тәмамланыр алдыннан Гафия апа Рәхимкулова барлык теләкләрнең кабул булуы—һәркемнең тормыш юлдашы, балаларының яу кырыннан исән-сау әйләнеп кайтуы өчен салават әйтә. Аллаһы Тәгалә бу теләкне кабул кыла: Җиңү көне җитә! Сөенечле хәбәрне ишетү өчен, барысы да радио янына җыела. Левитан Җиңү яулануын хәбәр итә. Бөтен халык шатлана, җырлый-бии. Исәннәр туган якларына әйләнеп кайта... Әмма күпләр яу кырында ятып кала. Балалары һәм оныклары бәхетле яшәсен, укый һәм эшли алсын өчен, үз гомерләрен кызганмый алар.

Әби оныгына әнисенең Киев янында җирләнүе хакында сөйли. Аның каберенә туган ягыннан алып килгән туфракны салу һәм рухына багышлап дога уку өчен, җәйге каникул вакытында шул якларга сәфәр чыгачаклар алар. Әлеге хатлар исә газиз кешеләренең каберен эзләп табарга ярдәм итәчәк. Әби белән оныгы бу хатларны кадерләп кенә портфельгә салалар. «Журавли» җыры астында Гөлфия Диникиева башкаруында Рафаэль Сафинның «Кыр казлары» поэмасы яңгырый. Яу кырыннан әйләнеп кайтмаган солдатлар батырлыгына гимн булып яңгыраган бу әсәр күңелгә үтеп керә. Поэманың шигъри юллары сугыш уты аша узган, якыннарының һәм туганнарының, дусларының үлемен үзе күргән кешеләр язмышы белән үрелә...

**Г.ГАЛЛӘМОВА, Бүздәк Мәдәният һәм ял үзәгенең методика кабинеты мөдире.**

Сотрудничаю с районной библиотекой: участвую в мероприятиях, готовлю выступления.

Встреча с Айдаром Закиевым-моим бывшим учеником, автором нескольких книг и молодым журналистом.



# Илһам чишмәләре—туган якта

**Буыннан буынга асыл хәзинә итеп тапшырыла торган, заман җилләре дә алалмый, гасырлар үтсә дә югалмый торган, кешелек тарихы өчен бик кадерле булган кыйммәтләр бар. Юк, асылташлар түгел. Бәясен берни белән дә үлчәп булмый торган, еллар үткән саен әһәмияте арта барган бу кыйммәтле хәзинә —китаплар. Якташларына шушы рухи байлыкны бүләк иткән Айдар Зәкиевның"Күбәләк канатлы бал корты" исемле икенче яңа китабының исем туе нәкъ менә шушы асыл сүзләр белән башланып китте.**



Бу көнне язучы белән очрашырга район китапханәсе Айдар Мидхәт улының иҗатын белгән, хөрмәт иткән, китаплары белән кызыксынган, татар теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә, әхлак темаларына битараф булмаган күпсанлы китап укучыларын җыйды. Әлеге очрашу көнен барыбыз да зур кызыксыну белән көттек. Шулай булмый ни, авылыбыз тарихында икенче китабын чыгарган һәм тиз арада үз укучыларын табып өлгергән яшь язучы,авылдашыбыз белән очрашу бит бу! Очрашуга китапханә хезмәткәре Гөлнур Мәүзир кызы Акчурина язучының тормыш һәм иҗат юлына багышланган бай эчтәлекле презентация әзерләде. "Айдар Зәкиевның иҗат дулкыннары" дигән китап күргәзмәсендә язучының төрле басмаларда дөнья күргән әсәрләре, китаплары урын алган иде.



Очрашу кичәсе ике өлештән торды. Беренче өлешендә игътибар үзәгендә якташыбызның балачагы, мәктәп, университет чоры, иҗаты булды. Кайчандыр Айдарның туган мәктәбендә тел һәм әдәбият укыткан, аның уңышлары белән бергә сөенеп, аны канатландырып һәм дәртләндереп торган Сания Кашфулловна да Айдарның иҗатка беренче адымнары хакында бик хисләнеп сөйләде. Әйе, Айдар Закиевны туган ягында, ул укыган Каран урта мәктәбендә яраталар, үз итәләр. Язучы белән очрашулар монда еш була. Бүгенге көндә мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыткан Зөлфия Җәмил кызы Мансурова язучы белән тыгыз элемтәдә эшли. Ул үзе дә мәктәптә укыганда Айдар белән төрле иҗади ярышларда бергә катнашуларын искә төшерде. Язучының яңа китабында урын алган "Ике җан","Тегермән","Би-би", "Күбәләк канатлы бал корты","Соңгы әкият" исемле хикәяләрне анализлады.

Очрашуда Айдарның класс җитәкчесе Асия Әхсәновна да катнашты. Бу классның бик тату, бердәм булуы, бергәләп уздырган кызыклы чаралар турында сөйләде. Истәлекле фотолар да алып килгән иде ул.

Очрашуда катнашкан классташларының күзләрендә Айдар белән горурлану, аңа соклану хисләрен күрергә мөмкин иде.

Менә сүз көтеп алынган кунак—язучы якташыбызга бирелде. Ул әсәрләренең язылу тарихын, истәлекле вакыйгалар хакында сөйләде.Барлык сорауларга бик теләп җавап бирде. Каран авыл Мәдәният йорты хезмәткәре Роза Шәрипованың Яңа Актауда туып үскән якташыбыз Ирек Габдрахманов иҗат иткән "Ташламагыз туган нигезләрне" , Рита Дистанова башкаруындагы "Дусларга"дигән җырлар очрашуыбызга тагы да ямь өстәде.

Әле Айдар Мидхәт улы иҗатының иң чәчкә аткан чоры. Без аның яңа әсәрен— "Күбәләк канатлы бал корты" китабын яратып кабул итәбез икән, димәк, аның иҗади киләчәге дә уңышлы булачак. Табигате белән тыйнак , гади күңелле, җор телле якташыбыз әдәбиятыбызда җуелмаслык тирән эз калдырырлык итеп туган халкына һәм туган теленә хезмәт итә.

Якташыбыз белән өч сәгатькә сузылган очрашу кичәсе җанлы, күтәренке рухта, дустанә мөнәсәбәттә, бер сулышта узып китте һәм безнең күңелләрдә җылы тәэссоратлар калдырды. Кичә ахырында очрашуга килгән авылдашлар автор имзасы куелган китаплар алдылар, аның белән бергә фотога төштеләр. Кичәдә катнашучылар бырысы да аңа үзләренең рәхмәтләрен җиткерделәр. Китапханә директоры Зөлфия Мидхәтовна язучыга истәлекле бүләк тапшырып, иҗат чишмәсенең саекмавын, безне—якташларын яңа әсәрләре белән куандырып торуын теләде. Без үз чиратыбызда якташыбыз Айдар Зәкиевка очрашуга кайткан өчен олы рәхмәтебезне белдерәбез, киләчәктә дә иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек телибез.

**Зөһрә АСКАРОВА,**
**Каран авылы китапханәчесе.**

## Мажаралы бәйге

***«Олимп» физкультура-савыктыру үзәге базасында беренче тапкыр «Форт Боярд» спорт-интеллектуаль бәйгесе үтте—16 катнашучы, 10 оештыручы, 2 сәгатьлек онытылмас уен***

Бүгенге көндә «Форт Боярд» янә актуальгә әй-



грамма" һәм башкалар көтте. Соңгы этап бу-

## Сәләтле кыз

**Гала-концерт белән тәмамланган «Музыка цифр» бөтенрусия конкурсы республиканың мәдәни тормышында чагу вакыйга булды. Бу бәйге талантлар смотры гына түгел, электрон музыка өлкәсендә үзләренең иҗади омтылышларын тормышка ашыручы балалар, студентлар һәм преподавательләр өчен чын-чынлап зур бәйрәмгә әй-**

# Провожу Уроки мужества.
# Автор научно-методической разработки «Урок мужества»



Собираю материалы об истории Каранской СОШ , являюсь руководителем научно-исследовательской работы «История Каранской СОШ» и социального проекта «История родной школы»



Вместе с учащейся 10 класса Фатхетдиновой Айсылу написали научно-исследовательскую работу по теме «История одной тетради» об учащихся 5 класса Каранской СОШ 1945-1946 учебного года. Заняли 1 место на районном этапе



◆ ХӘТЕР ҺӘМ ДАН ЕЛЫ

23.10.2020г.

# Бер дәфтәр тарихы

Узган елның көзендә Каран урта мәктәбе директоры Айрат Мансуров мәктәпкә бер дәфтәр алып килде. Мәктәптә капиталь ремонт башланган вакытта Айрат Флүр улы аны архив документлары арасыннан таба. Берничә дистә ел эчендә ул искереп беткән, яшел төсе сорыга әверелгән, төбе шнурланган. Уңган, кара таплары нннан „чәчәкләнеп" беткән дәфтәр кемнеңдер игътибарын җәлеп итмәс тә иде, мөгаен, әмма аның тышына язылганнар шунда ук кызыксыну уятты. Кайчандыр ак булган кәгазьдә матур, иркен почерк белән: „1945-1946 уку елына БАССР Бүздәк районы Каран урта мәктәбенең 5 классы журналы", — дип язылган.

Агымдагы елның сентябрендә бу дәфтәр дә 75 еллык юбилеен билгеләде.

Мин ул чактагы 5 класс укучыларының язмышлары һәм сугыштан соңгы беренче уку елының уку-тәрбия процессы үзенчәлекләре турында белергә булдым. Бер кечкенә генә дәфтәргә балаларның уку елы буена өлгереше турында барлык мәгълүматларның да керүе мине гаҗәпләндерде. Мин үз классымнан Айсылу Фәтхетдинованы ярдәмгә чакырдым. Өстәвенә, әлеге класс укучылары исемлегендә аның туганы — Зәкә-



һәм сугыш тәмамлануын тантаналы игълан иттеләр. Укучылар да, укытучылар да үксеп еладылар.

Сугыш вакытында ил иратларының шактый өлешенең гомере өзелү миллионлаган гаиләләр өчен бик авыр хәл була. Күпсанлы категория: тол хатыннар һәм ялгыз аналар барлыкка килә. Хатын-кызлар үз иңнәренә икеләтә бурычны йөкли: гаиләнең матди ягын һәм балаларны тәрбияләү турында кайгыртырга туры килә.

Дәресләрдән соң балалар ничек тамак туйдыруны кайгырталар. Сугыштан соң мәктәптә дә, өйдә дә әйбәт азык-төлек чыганагы ындыр-бакча була.

татар телендә язылган һәм алар шушы телдә укытылган. Шулай ук ул вакытта немец телен укыту кирәк булу-булмау турында бәхәсләр бик күп була. 1942-1943 уку елыннан барлык мәктәпләрдә дә махсус фән —дисциплиналы, физик яктан нык һәм чыдам егетләр әзерләүгә юнәлдерелгән хәрби эш кертелә. Бу фәнне фронтовик, табиблар династиясе башлыгы Әмирҗан Гаделшин укыта.

Без шушы бишенче класс укучыларының язмышы, аларның гаиләләре һәм хезмәт һөнәрләре турында күп нәрсә белдек. Безнең тарих геройлары: Зәкәрия Зәйнетдинов, Фәһим Зәйнуллин, Сәгъдулла Гарифуллин, Госсам Садыйков, Хәдис Хәбиров, Рифгать Фаткуллин, Нәҗия Җиһаншина, Раил Смаков һәм башкалар. Алар лаеклы гомер кичерәләр, гаилә коралар (Раил Смаковтан тыш), кызлар һәм уллар тәрбияләп үстерәләр.

Бу кешеләрнең тормышы турында күбрәк белгән саен, кайбер гаилә әгъзаларының язмышы тарихы безнең мәктәп белән тыгыз бәйләнгән булуына гаҗәпләнеп бетәлмәдек: алар бирелә эшләгәннәр яки әле дә эшлиләр. Болар — Заһит

КОПИЯ
ДИРЕКТОР
МАНСУРОВ
Подпись:

# Совместная работа с сельской библиотекой: читательские конференции, мероприятия, посвященные поэтам, писателям-юбилярам и знаменитым землякам.

## Редакция почтасыннан

## «Башкорт самородогы»

**Без тыныч, бәхетле тормышта яшибез. Ләкин моның күпме авырлыклар, корбаннар бәрабәренә ялануын онытырга хакыбыз юк.**



Каран авыл биләмәсе территориясендә яшәүче һәр кеше Башкорт республикасының чал тарихында чагу эз калдырган күренекле сәяси һәм дәүләт эшлеклесе Муллаян Дәүләтша улы Халиковның нәк менә безнең якларда, атап әйткәндә, Иске Актау авылында тууы белән хаклы рәвештә горурлана.

Каран урта мәктәбендә үткән башкорт теле атналыгының бер көне Муллаян Халиковка багышлануы да очраклы түгел. Чөнки без үзебез хәтерләү генә түгел, күренекле якташыбыз турындагы якты истәлекне киләчәк буыннарга да җиткерергә тиешбез. Чара авыл китапханәсендә үтте. Укучылар өчен китапханә "Башкорт самородогы" дигән стенд әзерләде.

Башкорт теле һәм әдәбияты укытучысы Зөһрә Ягъфәровна Фәрхетдинова балаларны якташыбызның тормыш юлы белән таныштырды. Укучылар Азат Валитов, Эльвина Хәбибрахманова, Айсылу Фәтхетдинова, Вилена Зарипова, Айсылу Биктимерова һәм Айгиз Харисов чыгышлары да Муллаян Халиков хакында булды.

Якташыбыз Муллаян Халиков—башкорт халкының милли дәүләтен төзүгә бик күп көч салган кеше. Аның гомере кыска, әмма ялкынлы була. Ул 27 яшендә Башкорт АССРы Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп раслана. Эшсеәрлеге, гади кешеләрне чын күңелдән кайгыртуы, халыкка намуслы хезмәт итүе абруй китерә аңа. 1920-1921 елгы корылык аркасында Башкортстан тарихында күрелмәгән каты ачлык башлана. Ачлыкның юлдашы булган ваба, тиф авырулары котырына. Казнада бер тиен акча юк. Шушы шартларда Халиков Олы Башкортстанны төзү буенча мөһим эшләр башкара. Республиканың чикләрен билгеләү, хокук нормаларын ачыклау өстендә эшли. Шуның нәтиҗәсендә Уфа губернасы Башкорт республикасына беренә. БАССРның башкаласы Стәрлетамактан Уфага күчә. Шулай итеп, Башкортстанда 8 кантон, алар эчендә 296 волость һәм 3272 авыл Советы булдырыла. Олы Башкортстанның Халык Комиссарлары Советы председателе итеп М.Д.Халиков тәгаенләнә. Халык һәм илтәшләре арасында зур абруй казана ул. Дәүләт эшлеклесе А.А.Биишев аны "башкорт самородогы" дип атый.

1925 елдан Муллаян Халиков Мәскәүдә яши һәм Финанс министрлыгында эшли башлый. 1937 елның 27 сентябрендә халык дошманы исеме ягылып, атуга хөкем ителә. Мәскәүнең Дон зиратында җирләнгән. Нибары 43 яшь була аңа! Хатыны Сара Закировна иренең "контрреволюцион эшчәнлеген яшергән өчен" кулга алынып, 8 ел төрмәдә утыра. 1958 елда Муллаян Халиков һәм аның хатыны реабилитацияләнәләр. Лагерьлар аша үтеп, исән калса да, Сара Халикована Уфада яшәргә ирек бирмиләр. Ул Свердловский өлкәсенә яшәргә китә, арытабангы язмышы билгесез.

Кешенең кем булуын беләсең килсә, аның илен, затын, әчәр суыны атамасын сораш, диләр. Иске Актау авылында яшәгән крестьян Дәүләтша Халиковның ишле гаиләсендә алты бала: Разыя, Әхмәтша, Мәрзия, Бикә, Муллаян һәм Тәхвәтша үсәләр. Бу авылда бүген дә аларның нәселен дәвам итүчеләр, аерым алганда,Тәхвәтшаның оныгы Фәнүз Халиковның улы Хәлил үзенең гаиләсе белән ата-бабалары нигезен яңартып яшиләр. Безнең чарада Хәлилнең балалар бакчасында эшләүче җәмгате Лиза Наилевна катнашты. Халиковларның шәҗәрәсенә байкау ясады ул. Фотографияләр белән эшләнгән бу шәҗәрә укучыларда зур кызыксыну тудырды.

Класс җитәкчесе, чит телләр укытучысы Асия Әхсәновна укучыларны үз нәселен белергә, бабалары турындагы истәлекләрне озакка сузмый язып барырга чакырды. Китапханә әзерләгән "Личность в башкирской истории—Муллаян Халиков" дигән видео чыгышларга йомгак ясады. Китапханәдә Халиковларның нәсел шәҗәрәсе, аның тормышы һәм эшчәнлеге турында китаплар, материаллар туплаңган папкалар да бар.

Башкортстан тарихында җуелмас эз калдырган данлы якташыбыз Муллаян Халиковның исеме буыннанбуынга олы горурлык белән тапшырылыр.

**Зөһрә АСКАРОВА,**
**Каран авылы китапханәчесе.**

---

Зөһрә АСКАРОВА, Каран авылы китапханәчесе.

Зиһидә КӘРИМОВА, «Зиһидә» башкорт халык фольклор ансамбле җитәкчесе.

Лена ГАЛИНА-МӨХТӘСИПОВА, Бүздәк авылы.

Динара РӘХИМОВА (ГАЛИУЛЛИНА), Нефтекама шәһәре.

27.03.2018 г.

## Әдәбиятыбыз аксакалы

**Күренекле башкорт шагыйре Нәҗар Нәҗминең тууына 100 ел тулу уңаеннан Каран авылы китапханәсендә "Әдәбиятыбыз аксакалы" дигән хәтер кичәсе үтте**





Зөһрә АСКАРОВА, Каран авылы китапханәчесе.

Участие в финале конкурса «Лидер 21 века».Моя ученица Насырова Элина признана победителем районного этапа конкурса.

# Яшь лидерлар

***Районда «XXI гасыр лидеры» Бөтенрусия конкурсының Яшьләр үзәге тарафыннан оештырылган финал этабы узды***




Әлеге конкурсның максаты—яшьләр арасында лидерларны ачыклау, шәхси үсеш һәм актив тормыш позициясе булган гражданинның уңай образын формалаштыру юлы белән аларга ярдәм итү.

Финалга безнең районнан иң актив, инициативалы, талантлы, иҗади, максатчан яшьләр җитте. Алар арасында Элина Насыйрова, Вадим Әхтәмов, Эмиль Баһаутдинов, Азамат Кулуев, Илина Сәитова, Илга Синенко бар. Алар үз эшчәнлекләре нәтиҗәләре хакында сөйләделәр, биремнәрне чиштеләр, сорауларга җавап бирделәр, шулай ук аудитория белән уен барышында үзләренең лидерлык сыйфатларын күрсәттеләр.

«Видеопрезентация» конкурсында бу яшьләргә үзләрен мәктәп үзидарәсе лидеры буларак күрсәтергә, мавыгулары һәм казанышлары, иҗтимагый эшләре тәҗрибәсе турында сөйләргә кирәк булды.

Каран авылыннан Элина Насыйрова—уку отличнигы, мәктәп яшьләре оешмасы лидеры, төрле дәрәҗәдәге фән олимпиадаларында, конференцияләрдә күп тапкырлар призер һәм җиңүче. Ул бик теләп фәнни-тикшеренү һәм проект эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Бик яхшы укуы өчен, 2018 елның декабрендә «Орленок» Бөтенрусия балалар үзәгенә юллама белән бүләкләнгән. Биергә, рәсем төшерергә ярата, «Городецкая роспись» түгәрәгендә шөгыльләнә, волейбол һәм баскетбол буенча мәктәп командасы әгъзасы ул. Район газетасына мәкаләләр яза.

укый, инглиз телен өйрәнә. Мәктәптә узган барлык чараларда да актив катнаша.

Шушы ук мәктәптән Илга Синенко рәсем ясарга һәм музыка коралларында уйнарга ярата. Ул мәктәп, район күләмендәге төрле чараларда, олимпиадаларда, конкурсларда катнаша. Чаралар өчен сценарийларны үзе яза.

Таулар авылыннан Эмиль Баһаутдинов мәктәп һәм район күләмендә узган чараларда актив катнаша. Иншалар һәм нәфис сүз осталары конкурсы җиңүчесе, мәктәпнең спорт клубы командиры, шулай ук «Мирас» бию коллективы әгъзасы ул.

Канлы-Төркәйдән Азамат Кулуев та— иҗади шәхес, һәрвакыт алга омтылып яши ул. Азамат—укучылар үзидарәсе командасы әгъзасы, күп кенә олимпиадаларда һәм конкурсларда актив катнаша.

Сабай авылыннан Илина Сәитова— төрле дәрәҗәдәге

җавап биреп, үз эрудицияләрен күрсәттеләр.

«Аудитория белән уен» конкурсы катнашучыларга үзләренең оештыру сәләтен һәм лидерлык сыйфатларын күрсәтергә мөмкинлек бирде.

Моннан тыш, бәйгедә катнашучылар командада эшли белүләрен дә ача алдылар. Жюри сүзләренә караганда, аларның һәркайсы үзен лаеклы күрсәтте.

Район хакимияте башлыгының социаль һәм кадрлар сәясәте буенча урынбасары Гөлфия Габдрәфыйкова барлык конкурсантларны һәм аларның җитәкчеләрен котлады, киләчәктә дә уңышлар теләде, барысының да яхшы нәтиҗәләр күрсәтүләрен һәм монда педагог-оештыручыларның өлеше зур булуын билгеләде.

— Бәйгедә катнашкан барлык яшьләр дә иҗадилар, талантлылар, акыллылар. Балаларның уңышларыннан



лырга ярдәм итәргә тиеш, — дип ассызыклады Гөлфия Ринат кызы.

Сынау нәтиҗәләре буенча жюри җиңүчеләрне ике яшь категориясендә билгеләде. 8-

урында Элина Насыйрова **(рәсемдә)**, икенчедә—Илга Синенко, өченче урын Эмиль Баһаутдиновка бирелде. Үзенчәлекле шушы бәйгедә катнашкан һәркемгә Мактау

# Участие в финале конкурсе «Лидер 21 века». Открытие года Волонтеров



## Волонтер елын ачу:

### 1нче Бүздәк урта мәктәбе базасында Бөтенрусия конкурсының муниципаль этабы финалы үтте

**Лидер исеме өчен көрәшергә алты кеше теләк белдерде. Аларны ике төркемгә бүлделәр: 8-9 һәм 10-11 класс укучылары. Беренчесендә Алина Сабитова (Каран), Тимур Нагаев һәм Ирина Басыйрова (2нче мәктәп) көч сынашса, икенчесендә Луиза Бәдретдинова (Сабай), Эльвина Газизова (2нче мәктәп), Алсу Абдурашидова (Гафури) сынау тотты.**



Чараны алып баручы—район хакимиятенең яшьләр эшләре буенча баш белгече Алия Усманова хәбәр итүенчә, алар сынауларның барлык этапларын уңышлы үткәннәр һәм финалга чыкканнар.

Бәйгедә катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, район хакимияте башлыгы урынбасары Гөлфия Габдрәфыйкова «Иди же выбранным путем» дигән шигырь аша изге теләкләрен җиткерде.



Финалистлар ике этапта үз сәләтләрен күрсәтергә тиеш иделәр: «Минем тормыш кредом» презентациясе һәм дебатлар. Жирәбә ярдәмендә кем артыннан кемнең чыгыш ясавы билгеләнде. Жюри баллар куйды. Һәр катнашучы сәхнәгә ялгызы яки ярдәмчеләре белән чыкты. Алар җырладылар, биеделәр, үзләре һәм тормыш кредосы турында сөйләделәр. Алдан төшерелгән видеоролик ярдәмгә килде. Мәсәлән, Алина Сабитова үзе гитарада уйнап, ахирәтләре белән «Бүздәк чияләре» җырын башкарды. Аның кумиры—Олимпия чемпионы Алина Заһитова икән, кыз республика горурлыгы булу турында хыяллана.

Луиза Бәдретдинова лидер—үзен башкалардан өстен куйган кеше түгел, ә башкаларны тыңлый һәм ишетә белгән кеше, дип исәпли. Лидер җиңгән өчен дә, эшне башкара алмаган өчен дә җаваплылыкны үз өстенә ала.

Тимур Нагаев «Мин һәм минем командам» дигән монолог әзерләгән. Аның өчен төп сыйфатлар—ышаныч, эшкә сәләтлелек һәм максатчанлык.

●●●

Дебатлар өчен бәйгечеләрне парларга бүлделәр: берсе тәкъдим ителгән теманың уңай, икенчесе кире ягын күрсәтте. Мәсәлән, волонтерлык яклылар һәм аларга каршылар. Кешеләргә ярдәм, изгелек кылу … .Каршылар—мохтаҗларга социаль ярдәм күрсәтүче дистәләгән оешма бар. Башка темалар—мәктәп формасы, өченче дәрестән соң 40 минутлык тәнәфес кирәкме, мәктәпне тәмамлаучыларны БДИга кадәр ике ай алдан укудан азат итәргәме, юкмы. Әзерләнү өчен вакыт бирелде. Аннары һәр катнашучы үз фикерен яклады.

Жюри рольләрне алмашырга тәкъдим итеп, бурычны катлауландырды. Бу юлы бик үк шома килеп чыкмады. Нәтиҗә: лидер кискен үзгәрүче хәлләрдә эш итәргә әзер булырга тиеш.

●●●

Жюри әгъзалары очколарны исәпләгән арада сәхнәдә «Биюнең чиге юк» конкурсында җиңгән Ангелина Гайнанова һәм Эльвина Газизова биюләр һәм җырлар башкардылар.

●●●

Фанфаралар яңгырый. Вердикт чыгарыр вакыт җитте. «XXI гасыр лидеры» конкурсында катнашучыларның кече төркемендә Тимур Нагаев лидер дип табылды. Өлкән төркемдә Эльвина Газизова җиңү яулады. Нәкъ менә ул конкурсның республика этабында район намусын якларга тиеш. Каран урта мәктәбе укучысы Алина Сабитова махсус приз белән бүләкләнде. Калган бәйгечеләргә катнашучы сертификатлары тапшырылды.

Чара азагында барысы бергә Волонтерлар гимнын башкардылар.

●●●

Конкурс тәмамланды. Лидерлар ачыкланды. Волонтерлар сафларына яңа әгъзалар кушылды. Бик күп матур сүзләр әйтелде, зур вәгъдәләр бирелде. Хәзер иң мөһиме—аларны тормышка ашырырга кирәк. Бер бәләкәй генә изге эш йөзләгән яңгыравыклы сүзләрдән күп тапкырга кыйммәт. Эшгамәлләребезгә тормыш үзе бәя куячак.

**С.МОРАТОВА.**

*Кем соң ул волонтер? «Волонтер» сүзе латынчадан «ирекле, теләк белдерүче» дигән мәгънәне аңлата.*

*Волонтерлык—дөньяның күп илләрендә күзәтелгән, тормышны яхшыртуга юнәлтелгән ирекле хәрәкәт, гуманлы граждannар җәмгыяте төзүнең мөһим өлеше булып тора ул.*

*Волонтер—ниндидер эшне ирекле рәвештә үз өстенә алган кеше.*

*Волонтерлар—ниндидер өлкәдә мәҗбүри түгел, ә үз ихтыярлары һәм ризалыклары буенча эшләүче кешеләр. Волонтерлык хәрәкәте—ниндидер мәнфәгать белән берләшкән кешеләрнең ирекле союзы ул.*

*Волонтерлар—җәмгыятьне һәрьяклы үстерүче кешеләр төркемнәре. Волонтерлар турыдан-туры җәмгыять белән эшләгәнлектән, аның проблемаларын яхшырак аңлыйлар һәм ишетәләр, аларны беренчеләрдән булып хәл итәргә тырышалар.*

◆ <u>ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ХАКЫНДА</u>

## Ышанычлы канат астында

Һәр гаилә сабыеның дөньяга килүен түземсезлек белән һәм сөенеп көтә. Кызганычка каршы, баланың авыру булып



елда Найлә Гизәровна баш врачның балалар саулыгы өчен җаваплы урынбасары итеп тәгаенләнә һәм әлегә кадәр

## Исәпләү приборын алыштыру турында

(Башы 1нче биттә)

Әйткәндәй, кулланучы моны теләсә һәм без тәкъдим иткән бәяләрне үзе өчен кулай дип тапса, счетчикларны «Башкирэнерго» һәм «ЭСКБ» җәмгыятьләре дә алыштыра ала. Безнең

**—Шулай да граждannарны счетчиклар алыштырырга мәҗбүр иткән оешмалар белән нишләргә соң?**

—Берничә киңәш бирәбез. Беренчедән, счетчик алыштырырга тәкъдим итүче кешеләр үзләрен «Башкирэнерго» җәмгыяте хезмәткәрләре дип танышты-

Участие в Вахте Памяти: подготовка и проведение литературно-музыкальной композиции, чествование ветеранов.



# Вахта памяти






# Участвую в поэтических вечерах: рассказываю стихи известных русских и немецких поэтов



## В прошлом году я выпустила 11 класс: Сабитова Алина и Хабибрахманова Эльвина были награждены медалью «За особые успехи»





39 лет в браке. С мужем вырастили и воспитали двух дочерей и сына. У всех высшее образование.





# Я любимая бабушка трех внучек и внука









Изучаю родословную семьи Нарбулатовых по архивным документам, монографиям. Участвую в научно-исследовательских конференциях по темам «Моя малая родина» и «Родословная семьи». Составила генеалогическое древо семьи Нарбулатовых





# Моя семья







# Моя семья





Амировская сельская библиотека муниципального бюджетного учреждения культуры «Буздякская централизованная библиотечная система» муниципального района Буздякский район Республики Башкортостан

**СЕРТИФИКАТ**

**Выдан**

*семье Самигуллиных*

**участнику онлайн фотоконкурса**

**«Наша дружная семья»**

**посвященного Всероссийскому**

**Дню семьи, любви и верности**

*Счастья, здоровья*

*и благополучия.*

**Директор МБУК Буздякская ЦБС**

**Валиуллина З.М.**

Спасибо за внимание!